Бүгенге санда:



Нурлатта тагы бер сквер булачак. 2 бит

# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга 10 июль 2015 ел

№ 50 (10579)

**11 июльгә һава торышы:** көчле яңгыр, җил көньяк-көнчыгыштан, 2 м/с; температура көндез +23°С, төнлә +17°С

# “Бердәм Россия” Рөстәм Миннехановны Татарстан Президентына кандидат итеп күрсәтте



**4 июльдә “Бердәм Россия”нең төбәк бүлекчәсе конференциясендә партия Рөстәм Миннехановны Татарстан Президенты постына кандидат итеп күрсәтте. Республика лидеры кандидатурасы өчен 99 процент делегат тавышын бирде.**

**Тулырак язманы “Атна вакыйгалары”ннан укыгыз**

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## *Абзац-информ*

### “ЗАРЕЧНЫЙ” АРМИЯГӘ ӨЙРӘТӘ

Бүген “Заречный” сәламәтләндерү лагере базасында ДОСААФ линиясе буенча “Ратный сбор” хәрби-патриотик юнәлештәге палаткалы лагеренда 3нче смена тәгәлләнде. Өч смена барышында барлыгы 150 мәктәп укучысы кыр шартларында хәрби-гамәли күнекмәләр һәм солдат тормышын үзләштерде.

### ИҢ МАТУРЫ НУРЛАТНЫКЫ

Россия Пенсия фондының Нурлат районы буенча бүлеге ландшафт дизайны һәм дизайн-интерьер буенча Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары идарәләре арасындагы конкурста беренче урынга чыкты. Җиңүче коллективка ПФРның Татарстан бүлеге управляющие Марсель Имамов имзалаган Диплом тапшырылды.

### ОСТАЛЫКТА СЫНАТМАГАННАР

“РИТЭК” җәмгыяте подразделениеләре арасында Волгоград өлкәсенең Котово шәһәрендә үткән осталык конкурсыннан “ТатРИТЭКнефть” ТППсы эретеп ябыштыручысы Ирек Хәйруллин беренче урынны алып кайткан. Гомумән, безнекеләр уңышлы чыгыш ясаганнар: командалар арасында икенче урынны яулаганнар.

### МУЗЕЙДА ЯҢА КҮРГӘЗМӘ

Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре тарихы төбәк музеенда Халыкара фотограф көненә багышланган күргәзмә ачыла. Күргәзмәдә төрле чор фоторәсемнәре, фотоаппаратлары һәм техника тәкъдим ителәчәк. Нурлатлылар күргәзмәгә үз өлешләрен кертеп, район һәм шәһәр тормышына кагылышлы фоторәсемнәрен уртаклаша алалар.

### ВАКЫТЫННАН АЛДА ЯЗЫЛУ БАРА

**1 июльдән район газетасына <u>2016 елның I яртыеллыгына 2015 елның II яртыеллыгы</u> бәяләреннән язылу башланды. “Дуслык” белән элеккеге бәяләрдән аралашуыгызны озайтырга ашыгыгыз!**

АКТУАЛЬ

# Кем эшләми, компенсация алмаячак

**Бүгенге көннән балалар бакчасы өчен ата-аналар өлешен өстәмә компенсацияләүгә документлар җыю буенча мобиль офислар яңадан эшли башлый.**

Ата-аналарга уңайлы булсын өчен һәм, әлбәттә, вакытларын экономияләү максатыннан, мобиль офислар эше гариза бирүчеләр саны 20дән арткан 7 балалар бакчасында график буенча оештырыла. Болар – Бала үсеше үзәге, “Чишмәкәй”, “Чыршыкай”, “Чык тамчысы”, “Тирмәкәй”, “Светлячок”, “Камыр Батыр” һәм “Әкият” бакчалары. Белгечләр документларны кичке 4тән 6га кадәр кабул итәчәк.

– Балалары башка бакчаларга йөрүче ата-аналарга документларын үзләренә 33нче Республика матди ярдәм үзәгенә тапшырырга кирәк булачак, – дип билгеләп үтә компенсацион түләүләр бүлеге мөдире Әлфия Сараева. – Без персональ мәгълүмати битләр әзерләдек, аларда документлар тапшыру тәртибе, урыны һәм вакыты билгеләнгән.

Исегезгә төшерәбез, документлар пакетын ярты елга бер тапкыр яңартырга кирәк. Бу, нигездә, соңгы 3 ай өчен хезмәт хакы турында белешмәләргә кагыла. Чөнки өстәмә компенсациягә бары тик керемнәре гаиләнең һәр әгъзасына 20 мең сумнан артып китмәгән гаиләләр генә исәп тота ала. Әмма бу эти-әниләрнең берсе рәсми рәвештә эшләмәүче гаиләләргә кагылмый. Бу очракта алар бары тик төп компенсациягә генә исәп тота ала: беренче балага 20, икенчесенә – 50, өченче һәм аннан соңгы балаларга 70 процент ул. Бу – федераль дәрәҗәдәге социаль гарантия. 1 июньгә булган мәгълүматлар буенча, Нурлат районында төп компенсацияне балалар бакчасында тәрбияләнүче 2958 баланың эти-әнисе ала, аларның 1329ы үзләренең өстәмә компенсациягә хокуклы булуын раслаган. Аның күләме бала бакчага йөргән өчен түләгән суммадан һәм гаиләнең керемнәреннән чыгып, 200 сумнан 1200 сумга кадәр тәшкил итә.

Маргарита ЛИТТА

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

ПАРКЛАР ҺӘМ СКВЕРЛАР ЕЛЫ

## Исемсез скверның икенче яшьлеге

**Бүген Сәлимҗанов урамының 13нче йортында яшәүчеләрнең нәкъ тәрәзә каршыларындагы иске сквер яңа сулыш алып килә.**

Аның икенче тормышы "СтройГранд" подрядчы оешмасы килү белән башланды. Аларның яшел зоналарны төзекләндерүдә тәҗрибәләре бар инде. Мисалга да ерак йөрисе юк. Әле ике атналап элек кенә алар шикәрчеләр бистәсендәге "Дуслык" скверын төзүне һәм Владимир Медведский исемендәге паркка реконструкция ясауны тәгәлләделәр. Шәһәрлеләрнең рәхмәт сүзләре исә әлеге оешма төзүчеләренә Сәлимҗанов урамындагы скверда да эшләрне сыйфатлы һәм үзвакытында башкарырга яхшы этәргеч булыр, мөгаен.

Биредә кирпеч аркалар, бетон клумбалар һәм эскәмияләрне сүткәннәр инде. Берочтан элеккеге фонтан резервуарын да алачаклар. Районның архитектур планлаштыру һәм шәһәр төзелеше идарәсе дизайнеры Елена Мингалимова проекты буенча, территорияне брусчаткадан җәяүлеләр сукмаклары һәм чәчәк газоннары бизәячәк. Скверга уңайлы эскәмияләр куелачак, алар янәшәсенә кечерәк кенә чүп савытлары да урнаштырыла, ди. Заманча яктырту баганалары да интерьерны тулыландырачак.

– План буенча, шәһәрдәге барлык парк-скверлар, шул исәптән Сәлимҗанов урамындагы сквер да 20 августка кадәр файдалануга тапшырылырга тиеш. Эшләр график буенча алып барыла, материал сатып алынган, шуңа да сроклар буенча тоткарлыклар булырга тиеш түгел,




СКВЕРДА ДЕМОНТАЖ ЭШЛӘРЕ БАРА

– ди "СтройГранд" төзелеш компаниясенең генераль директоры Илдар Кәлимуллин. – Бу объектта төп кыенлыклар иске конструкцияләрне сүтүгә бәйле, әйтергә кирәк, аны ясауга үтә дә намуслы караган булганнар. Бездә дә сыйфат әйбәт булачак.

"Һәр шәһәр кешесенә яшел парк яки сквер янәшәсендә яшәве яхшы, әлбәттә, базарга килүчеләр дә биредә рәхәтләнеп ял итә алачак, – дип үз фикерен белдерде Самара өлкәсеннән килгән кунак Лидия Кузьмина һәм шуңа да ук теләген дә җиткерде. – Скверга матур исем бирү дә начар булмас иде. Юкса, исемсез сквер булып чыга бит.

Мин Нурлатта еш булам, асылда, базарда урман нигъмәтләре белән сату итәм, һәм скверны ничектер атаганнарын бер дә ишеткәнем булмады".

Чыннан да, ни өчен нурлатлылар арасында әлеге скверга исем уйлап табу буенча конкурс уздырмаска ди? Чөнки ул тиздән очрашулар, ял итүләр өчен ымсындыргыч урынга әвереләчәк бит. Хәер, матур урыны гына булсын, ә ул инде һич тә буш тормас, анысы.

Маргарита ЛИТТА

ХӘБӘРЛӘР

### ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘ[...] РЕЖИМЫ КЕРТЕЛ[...]

**2015 елның 1 июленнән махсус к[...] сәтмәгә кадәр Нурлат районында [...] республиканың 27 районында гад[...]тән тыш хәл режимы кертелде һәм [...]дый очракта эш итүнең төбәк (муни[...]пальара) дәрәҗәсе билгеләнде.**

Мондый карарга Татарстан Президен[...] вазифаларын вакытлыча башкару[...] Рөстәм Миннеханов кул куйды. Әлеге д[...]кумент кысаларында, районда гадәтт[...] тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияла[...] янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү б[...]енча комиссияләрнең, куркыныч табига[...] казаларының нәтиҗәләрен җиңеп чы[...] чараларын башкару өчен җәлеп ителү[...] көчләрнең эшче төркемнәре составы ачы[...]клана. Гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләре[...] бетерү буенча чаралар комплекс[...] эшләнә.

Сирень СӘМӘРХАНОВ[...]

### "АЛТЫН КОРТ" КУРКЫНЫ[...] ТУДЫРА[...]

**Россельхознадзорның Нурлат ра[...]онара бүлеге районда алтын бәрәң[...] нематодасы таралмагае, дип борчыла[...]**

– Узган елда алтын бәрәңге немато[...]дасы Якушкино авылындагы 33 су[...]тыйлы шәхси участокта табылган иде[...]. Хуҗасы бәрәңгене базардан, тиешле[...] документлары булмаган билгесез зат[...]лардан сатып алып утырткан булган, –[...] ди районара бүлек начальнигы Николай[...] Ларионов. – Алтын бәрәңге нематодасы[...] – бәрәңге һәм помидорлар тамырларын[...]да үрчи торган вак корт, ул әлеге культура уңышының 90 процентка якынын юк итәргә сәләтле. Әлеге карантинлы объект бәрәңгене генә түгел, паслен-чалылар семьялыгыннан булган башка үсемлекләр: помидор, баклажан, борычка да кичәргә һәм юк итәргә мөмкин. Өстәвенә, бик тиз, хәтта аяк киеменә эләккән туфрак яки җил, агымсулар белән дә таралырга сәләтле. Шуңа да әлеге шәхси участок хуҗасына бу җирдә бернича ел дәвамында берни үстермәскә кушылган, авыл җирлеге башлыгына моны контрольдә тотарга дигән предписание дә бирелгән иде. Әмма тикшерү боларның үтәлмәвен күрсәтте, хуҗа кеше бу урында быел да бәрәңге һәм чөгендер үстерә. Шуңа да бу очрак уңаеннан тиешле чаралар күрергә мәҗбүр булачакбыз.

Россельхознадзорның районара бүлеге начальнигы бу уңайдан бәрәңге үстерү белән шөгыльләнүче хуҗалыклар һәм шәхси затларның да игътибарлырак булуларын һәм бу карантинлы объектның таралуына юл куймауларын сорый.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

### ЯШЬЛӘР ИҖАДИ ФЕСТИВАЛЬДӘ

**Нурлатның эшләүче яшьләре үзләрен "Наше время – Безнең заман" III республика иҗат фестивалендә сынап карый алачак.**

– Конкурста быел коллективлар гына түгел, аерым башкаручылар да катнаша, – ди район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге әйдәп баручы белгече Наталья Тюкаева. – Узган ел әлеге фестивальдә безнең районнан "Ледок" спорт мәктәбенең талантлы яшьләре катнашып, бүләк алып кайткан иде. Фестивальгә 18-35 яшькәчә эшләүче талантлы яшьләр заявка бирә ала. Фестивальнең сайлап алу турлары сентябрь-октябрь айларында узачак. Заявкалар 31 августка кадәр кабул ителә.

Зилия ӘКСАНОВА

ЯШЬЛӘР

### УКУЧЫЛАР ПРЕЗИДЕНТ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

**Районның 23 сәләтле укучысы – фән олимпиадалары призерлары, фәнни конференцияләр, иҗади конкурслар җиңүчеләре "Сәләт – 2015" халыкара яшьләр мәгариф форумында катнаша. Быел анда Татарстан, Россия һәм чит илләрдән 5 меңнән артык кеше җыелган.**

– Чара 7-12 июльдә уза, - ди районның "Яңа буын" балалар иҗтимагый хәрәкәте кураторы Миләүшә Мөхәммәтова. – Форумның беренче көнендә үк Республика лидеры Рөстәм Миннеханов белән очрашу аеруча истә калды. Әлеге чара республикада 21 ел рәттән үткәрелә. Программага старт беренче тапкыр Арча районында бирелгән булган. Биредә, Биләр изге җирендә төрле илләрнең талантлы балалары, лидерлары очраша, аралаша, тәҗрибә уртаклаша. Ә яшьләр бик актив. Лагерь да елдан-ел киңәя, матурая. Программа да бик бай: интеллектуаль-спорт эстафеталары, КВНнар уза, "Нәрсә? Кайда? Кайчан?" интеллектуаль уены магистры Ровшан Аскеровның да килүе көтелә. Моннан тыш, безнең Нурлат яшьләре тагын бер истәлекле вакыйгада – ел әйләнәсе эшләүче фәнни-мәгариф үзәкне ачуда да катнашачак.

Зилия ӘКСАНОВА

КАБУЛ ИТҮ

## Проблемалар депутатка китерә

**Татарстан Дәүләт Советы депутаты Илгиз Салиховның сишәмбе көнне узган чираттагы кабул итүенә 14 сайлаучы килде.**

Мөрәҗәгатьләрен язма рәвештә җибәрүчеләр дә аз түгел иде. Депутат аларын да карый, өйрәнә, төшенкелеккә бирелгән кешенең проблемасын хәл итү юлын эзли.

Депутат янына проблемаларын уртаклашырга шәһәрлеләр генә килми. Мисал өчен, бу юлы Төрнәстән бер ханым булды. Ул котылгысыз хәлдә калган – бер генә банк та аңа кредит бирми икән. Сәбәбе бар – кредит тарихы яхшылардан түгел. Әлеге хатын-кыз крестьян-фермерлык хуҗалыгын үстерү өчен инвестор эзләүдә булышуларын сорап килгән иде.

Бу юлы сайлаучылар арасында торак проблемасы белән килүчеләр дә аз булмады. Ә конкрет җавап бирә алу өчен кабул итүгә район башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы Лилия Закированы да чакырганнар иде. Мәсәлән, Мамыктан бер ир-ат, эксплуатациягә кертү өчен, йортын рәсмиләштерүдә ярдәм итүләрен сорады. Депутат янына консультация алыр өчен языучылар да булды. Чишмә поселогыннан берәү улын нефть вузына кертү өчен максатчан юллама алып булмыймы, дип кызыксынды.

– Хәзер барлык чыгарылышлар да уку йортларына БДИ нәтиҗәләре буенча кабул ителә, – диде Илгиз Салихов. – Улыгыз башта укырга керсен, аннан инде максатчан укыту вариантларын карарбыз.

Нурлаттан 45 ел хезмәт стажлы пенсионерны хезмәт ветераны статусы алу мәсьәләсе кызыксындыра иде.

– Стаж – андый статус алудагы шартларның берсе генә, моннан тыш, "Хезмәт ветераны" исемен алу өчен федераль әһәмияттәге бүләк булу да зарур, – дип аңлатты депутат. Бу хакта иң башта әлеге мөрәҗәгать итүче кеше күп еллар хезмәт куйган предприятие җитәкчелеге кайгыртырга тиеш иде, әлбәттә.

Бу юлы кабул итүгә язылган бер нурлатлыны бирегә бәла алып килгән: быелның июлендә аның йорты янган.

– Ярдәм итәрбез, – диде Илгиз Салихов һәм шулай ук янгын факты буенча бер тапкыр бирелүче ярдәм сорап район башкарма комитетына мөрәҗәгать итәргә дә киңәш бирде.

Кабул ителүгә язылган Нурлаттан бер хатын-кыз йортының түбәсеннән су үтүдән зарланды, башка проблемалары да бар иде. Ул йортларының авария хәлендә дип табылуы, ә хәзер аны бу категориядән янә кире күчерүләре турында сөйләде. Эш шунда, әлеге йортта яшәүчеләрнең кайберләре аны карап кына тормаганнар, ә яхшыртуны да кайгырталар, мәсәлән, капиталь ремонт ясыйлар, реконструкция үткәргәннәр, һәм хәзер бу йортны авария хәлендә дип әйтүе кыен. Әмма башкалар да бар – андыйлар үз торакларын карап торуны бер дә кайгыртмыйча һәм аны саклау буенча бернинди чаралар да күрмичә башка фатирга күчерүләрен көтеп яшиләр...

Һәр кабул итү сайлаучыларның яңа проблемаларын ача. ТР Дәүсоветы депутатының Нурлат сайлаучыларын Илгиз Салиховның чираттагы кабул итүе сентябрь аенда булачак.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

# ЯҢАРТЫЛГАН ЭССЕН ИШЕКЛӘРЕН АЧА

**Кибеткә йөрергә яратучылар һәм бу эшне яхшы белүчеләр өчен шәп яңалык: Нурлат шәһәрендәге ЭССЕН гипермаркетында реконструкция тәмамланды. Яраткан гипермаркеттаниләр үзгәрде һәм ЭССЕНга йөрү ни өчен тагы да уңайлыракка әверелде – бу хакта түбәндәге язмадан укырсыз.**

**ЭССЕН** – Идел буенда иң эре гипермаркетлар челтәренең берсе. Аның Татарстан буенча һәм аннан читтә 22 гипермаркеты бар. Бүгенге көнгә барлык кибетләрнең гомуми мәйданы йөз мең квадрат метрдан артып китә! Көн саен ЭССЕН гипермаркетларында 200 меңнән артык сатып алучы була.

Нурлаттагы ЭССЕН гипермаркеты 2005 елның маенда ачылган иде. Шул еллар эчендә нурлатлылар өчен ашамлык яки көнкүреш товарлары сатып алу күңелле гадәткә әверелде. Әмма вакыт үз урынында тормый, һәм Татарстанда иң динамикалы үсүче компанияләрнең берсе булган ЭССЕН үз сервисындагы һәр нечкәлекне камилләштерүен дәвам итә. Реконструкция, һичшиксез, шәһәрлеләрдә матур тәэсирләр уятыр – ЭССЕН командасының көче белән гипермаркет тагы да уңайлыракка әверелде, анда күп яңалык кертелде.



## СЮРПРИЗЛАР БУСАГАДАН БАШЛАНА

Хәзер ЭССЕН беренче катта урнашачак, бу сатып алуларга киткән вакытны кыскартачак. Икенче катны тулысы белән арендаторлар биләячәк.

Яңартылган гипермаркет булдыру өчен ЭССЕН хезмәткәрләре бары тик иң яхшы идеяләрне генә сайлап алдылар. Яңартылган кибетнең залын бизәү белән тәҗрибәле дизайнерлар шөгыльләнде. Кибеткә йөрү көндәлек мәшәкатькә әверелмичә, канәгатьлек хисе китерергә тиешлеге расланган. Товарларны югарыда сакламаучы якты сәүдә залы, яктылык-диодлы лампалы яңа түшәмнәр, яңартылган идәннәр, сыйфатлы җилләтү системасы – болар яңартылган ЭССЕН гипермаркетының кайбер нечкәлекләре генә әле.

Гаилә бюджетын экномияләргә теләүче сатып алучылар өчен ваклап үлчәүгә киң товар ассортименты куелган. Биредә төрле ярмалар, макарон эшләнмәләре, киптерелгән җиләк-җимеш, чикләвекләр һәм камыр ризыклары бар.

Кирәкле товарны табуы да җиңел булачак. Хәзер ашамлыклар, көнкүреш товарлары, уенчыклар, киемнәр һәм башка бик күп нәрсә сатып алучы өчен бик җайлы урнаштырылган.



## ТИЗРӘК, ТӘМЛЕРӘК, УҢАЙЛЫРАК

Теләсә кайсы кешедән, кибеттә иң элек нәрсәгә игътибар бирәсез, дип сорасаң, һәркайсы диярлек, башка факторлар белән беррәттән "искә", дип җавап бирер иде. Яңартылган ЭССЕНда исә ит деликатеслары һәм яңа пешкән икмәк исе таралган.

Хәзер Нурлатта да ЭССЕН гипермаркетында барлык сатып алучыларны да "Өй кухнясы" бүлеге сөендерер. Күп төрле эчлекләр белән гаҗәеп пироглар, салатлар, ярымфабрикатлар, иттән, балыктан һәм яшелчәдән әзер ризыклар, тандырдан хуш исле җәймәләр бераүне дә битараф калдырмас.

Тиз, тәмле, экономияле! "ЭССЕНның өй кухнясы" сере биредәге ризыкларның өй рецептлары буенча әзерләнүендә. Башка шәһәрләрдә ЭССЕНның канәгать калган сатып алучыларыннан еш кына: "пылаулары әнинеке сыман" яки "тавыкны ресторанннан да шәп пешерәләр", – дигән сүзләр ишетергә туры килә. ЭССЕНның аш-су осталары һәм кондитерлары даими рәвештә квалификацияләрен күтәреп һәм укулар узып торалар. Сезнең өстәлгә китерелүче ризыклар тәмле һәм тазә булсын өчен, заманча җиһаз куелган, ул ризык әзерләүнең бар процессын җентекле контрольдә тотарга мөмкинлек бирә.

**ЭССЕН** үз клиентларына һәрвакыт ярдәм итәргә әзер. Үз клиентларыңның сүзләренә колак сала белү – ЭССЕНның төп бурычларыннан берсе. Сатып алучыларыбыз ярдәмендә ЭССЕН көн саен камилләшеп тора, яңа идеяләр таба һәм барлык дәгъваларга һәм тәкъдимнәргә игътибар бирә.

*Акцияләр һәм тәкъдимнәр турында җентеклерәк эссен.рф сайтыннан, ЭССЕН гипермаркетында яки 8-800-100-62-62 кайнар линия телефоны аша белергә була.*

**2015 елның 15 июлендә Нурлат шәһәренең барлык халкын һәм кунакларны Гыйматдинов ур., 71Адагы яңартылган ЭССЕНны бәяләргә чакырабыз! Ачылу көнендә сезне "ЭССЕН. Моя семья" картасы буенча сатып алганда икеләтелгән бонуслар көтә. Шулай ук меңләгән төрдәге товарлар, ташламалар, төрле акцияләр, отышлы тәкъдимнәр, сюрпризлар һәм тагы бик күп нәрсә каралган. Рәхим итегез!**

Реклама хокукында



ТАТАРСТАННЫКЫН САТЫП АЛ!

# Өстәлгә килгәнче...

**Җәй Нурлатның җирле җитештерү предприятиеләре эш тәртибенә дә үзгәрешләр керткән.**

Әнә, "Нурлат сөте"нең сөт заводында катык һәм кефирны июнь аенда 16шар тонна җитештергәннәр. Бу, әлбәттә инде, әлеге продуктларга халык арасында ихтыяҗ арту белән бәйле.

Сөт заводына беренче партия сөт иртәнге 7нче яртыда ук килеп җитә. Сөтне исә гадәттәгечә лаборант каршы ала. Әнә, бу юлы да Лилия Һадиева сөт үрнәге алып, тизрәк аның составын: майлылыгы, аксымы, тыгызлыгы, чисталыгы, әчелеге һ.б.ларны өйрәнергә кереште. Җәйге эсселәрдә соңгысына игътибар аеруча җитди, ни дисәң дә, сөт – температура үзгәрешләренә бик сизгер продукт бит.

– Бу яктан быел проблемалар чыкканы юк. Хуҗалык бүлекчәләрендә сөт суыту җайланмалары бар, вак хуҗалыклар да сөтне суыткычларда саклый. Барлык сөт тә сыйфатлы булып килә, – ди эш арасында лаборант.

Анализлар яхшы, димәк, сөтне бушатырга да була, һәм эш оператор Рабига Гайнетдинова кулына күчә. Китерелгән барлык сөтне кабул итеп алучы кеше ул. Әмма вазифасы моның белән генә чикләнми, суынган сөтне махсус фильтрлар ярдәмендә чит катнашмалар һәм исләрдән арындырырга да, сепаратор аша үткәрергә дә өлгерә. Моннан тыш, зур суыту танкларын идеаль чисталыкта тоту да кирәк. Сөт заводында инде 9 ел эшли Рабига ханым, шуңа да үз вазифасында чын һөнәрмән.

– Минем бурыч – бар җирдә дә чисталык булдыру һәм бар эшне дә тиешле таләпләр буенча башкару, – ди ул.

Сөт, пакетларга тутырылганчы, җитештерүнең һәр этабында тикшерү үтә. Бу юлы да лаборант анализларны ясады һәм чираттагы этап – пастеризацияләүгә озатты.

– Без сөт продукциясен бары тик пастеризацияләү ысулы белән генә әзерлибез, – дип чираттагы этап белән таныштыра җәмгыять директорының сөт эшкәртү буенча урынбасары Алексей Аладин. – Пастеризацияләгән сөттә витаминнар, файдалы матдәләр һәм бактерияләр стерильләштерелгәненә караганда күбрәк. Моннан тыш, бернинди өстәмәләр, консервантлар да кушылмый.

Сөт заводында 12 төрдә сөт ризыклары җитештерелә бүген, шуңа да көн буена әле бер, әле икенче участокта эш кайный. Әнә, фасовкалау җайланмасында әле кичтән әзерләргә куелган кефирны пакетларга тутыруны тәгалләп киләләр. Организм, нигездә ашкайнату өчен файдалы булган бу әчетелгән эчемлеккә халык арасында ихтыяҗ арткаңнан-арта бара – әнә, бу көннәрдә 2000ләп данә җитештерәләр аны. Ул да түгел, мастер Алсу Усманова аппаратны катыкны термостат ысул белән фасовкалауга көйли башлады. Заводта продукцияне әлеге ысул белән җитештерүгә узган елда гына керештеләр әле, әмма стаканнарга тутырылган мондый сөт продукциясе дә үз кулланучыларын тапты.

Әлбәттә инде, җәй – мул сөт чоры, заводка бу чорда сөт бирмәбер артыграк килә. Әнә, көн саен 25 тонналап сөтне кабул итеп, эшкәртергә өлгерәләр заводта. Әле җәй башында гына моңа кадәр сыек ягулыкта эшләгән котельняларында пар генераторы эшләтеп җибәрүләре дә файдага булды. Сөтнең күп өлеше, әлбәттә инде, үзләренең база хуҗалыгы – "Нурлат сөте"ннән керә, сөт җыю белән шөгыльләнүче эшмәкәрләр арасында да сөтне җирле заводка тапшыруны хуп күрүчеләр шактый. Соңгы араларда гаилә фермаларында яки шәхси ярдәмче хуҗалыкларында җитештерелгән сөтне арадашчыларсыз, үзләре үк китереп тапшыручылар да арткан. Вак хуҗалыклардан сөт кабул итү завод өчен бераз мәшәкатьлерәк булса да, аларны да кире бормыйлар, чөнки бу җирле җитештерүчеләр файдасына бит.

Сөт заводында эш көне исә әле моның белән генә тәгалләнми. Зур май ачлагычта май өлгереп килә, сөт фасовкалыйсы, эремчек, әчетелгән ризыкларның әзерлек процессын контрольдә тотасы бар... Ә аннан завод логотибы төшерелгән машиналар продукцияне районның мәгариф учреждениеләре, җәмәгать тукландыуы предприятиеләре, кибетләргә таратырга чыгып китәчәк. Сөт ризыклары нурлатлылар өстәленә тазә килеш, вакытында барып ирешергә тиеш.




РАБИГА ГАЙНЕТДИНОВА ЗАВОДТА ИҢ ТӘҖРИБӘЛЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРДӘН

Лилия **МӨБАРӘКШИНА**


**"НУРЛАТ СӨТЕ"**ннән киң ассортиментта сөт һәм сөт ризыклары: *май, кефир, ряженка, эремчек, снежок, ацидофиллы эчемлек һ.б.лар сатып алыгыз!*



*Сыйфатлы һәм файдалы ризыкка өстенлек бирүчеләр һичшиксез "Нурлат сөте" продукциясен сайлый!* **Тел. 90-135.**

Реклама

СПОРТ

# Нурлат футболчыларын федерация дә хуплый



Автор фотосы

АЭРОПОРТТАГЫ ФУТБОЛ МӘЙДАНЧЫГЫ ТАТАРСТАН БЕРЕНЧЕЛЕГЕН КАБУЛ ИТӘРГӘ ДӘ ӘЗЕР

**Июнь азагында футбол буенча район чемпионаты старт алды. Быел турнирда “Сахарник”, АТП-1, АТП-2, “Нурлатнефть” НГДУсы һәм Егоркино командалары көч сынаша.**

Чемпионат, гадәттәгечә, ике әйләнештән торачак. Бүгенге көнгә беренче әйләнешнең өч туры тәгәлләнде инде. Сишәмбе көнне бу этапның иң төп матчларыннан берсе узды. Моңа кадәр бер җиңелү ачысы да татымаган Егоркино һәм АТП-1 командалары очрашты. Традиция буенча, әлеге командалар арасындагы уеннарның һәркайсы чамадан тыш киеренке уза, бу юлы һәр командадан икешәр уенчының “кызыл карточка” алуы да шуны раслый. Нәтиҗәдә, беренче таймда Руслан Сафин керткән бердәнбер гол “автотранспортчыларга” җиңү алып килде, һәм АТП-1 тугыз очко белән әлегә турнир таблицасының иң башында урын алды. Егоркинолылар алты очко белән икенче урында, өч очколы “Сахарник” өченче баскычта. Ә менә АТП-2 һәм “Нурлатнефть” әлегә бер генә очко да туплый алмадылар. Хәер, “нефтьчеләр”нең футбол кырына чыга алганнары да юк әле. Кызганычка каршы, уенчылары тупланып бетә алмаганлыктан, алар ике “техник җиңелүгә” дучар булдылар.

Әлбәттә, район беренчелегендә биш команда гына катнашуы әлләни саллы күрсәткеч түгел. Әмма бүгенге көндә тулы команда туплый алып, беренчелекнең башыннан азагынача темпны киметмичә уйный алганнарының энтузиазмына сокланырлык. Мәсәлән, АТП ничә ел рәттән инде икешәр команда белән чыгыш ясап килә. Бүгенге көндә Татарстан беренчелегендә уйнаучы “Факел” җыелма командасының да төп өлешен “автотранспортчылар” тәшкил итә.

– Иң мөһиме, егетләрнең теләкләре бар, – ди команданың җитәкчесе Марат Хәмидуллин. – Әлбәттә, кайгыртучан ярдәмчебезнең өлешен дә әйтми булмый. Нурлат АТПсы җитәкчесе Идрис Кәримов булышлыгы белән узган ел ике командага да яңа формалар алдык. Идрис Габделбәрович АТП командасының, “Факел”ның нәтиҗәләре, хәлләре белән дә һәрдаим кызыксынып тора.

Елның-елында беренчелекнең район статусын күтәрүче бердәнбер авыл командасы – Егоркино егетләренә ничек сокланмыйсың ди? Егоркинолыларның Нурлатта футбол пәйда булганнан бирле район беренчелегендә катнашмый калганнары юк. Ә бит Нурлат футболының тарихы 78нче яшенә аяк басты быел. Команданың тренеры Александр Ендиряков күпьеллык традицияләрне саклый алуларына сөенә. Әмма бу җәһәттән үзенең өлешен тыйнак бәяли.

– Үзем генә мин берни кыра алмыйм, – ди Александр. – Егетләр һәр елны, әйдәгез, команданы туплыйк, әзерләнә башлыйк, дип үзләре киләләр. Командабыз составында укучылар, ялга кайткан студентлар, эшчеләр дә бар. Менә быел да үз көчебез белән футбол мәйданчыгын әзерләдек, уеннарга да үз транспортыбыз белән йөрибез.

Быелгы турнирның мөһим яңалыгы да бар – чемпионатка район тарихында беренче тапкыр профессиональ арбитр хөкемдарлык итәчәк. Анатолий Фадькин – Нурлат егете, заманында беренче мәктәпне тәмамлаган, Нурлат командалары составында футбол да уйнаган. Аннан Казанда һәвәскәрләр лигасында чыгыш ясаган. Шунда ук Татарстан футбол федерациясе аша Футбол арбитрлары мәктәбен тәмамлап, тиешле таныклык алган, аңа “Спорт буенча хөкемдар” категориясе бирелгән. “Казан, Татарстан беренчелекләрендә арбитр булып эшләгәнем булды, әмма туган районым чемпионатында беренче тапкыр хөкемдарлык итәм. Әлбәттә, командалар күбрәк булса әйбәт анысы, әмма булганнары районда иң көчлеләре, һәм әлегә һәр матч мавыктыргыч, кискен көрәштә уза. Иң сөендергәне – командаларда яшьләр күп”, – дип чемпионаттан алган беренче тәэсирләрен уртаклашты Анатолий Фадькин.

Чыннан да, бүген район чемпионатында, сезон дәвамында башка турнирларда чыгыш ясаучы футболчыларыбызның оптимистлыгы күпләргә үрнәк булырлык. Әнә бит, стадион юк, дип ялгыш кына да “балавыз сыккан-нары” юк аларның, шикәрчеләр бистәсендәгесен дә хәлләреннән килгәнчә рәткә китереп торалар, узган ел исә аэропорт территориясендә футбол мәйданчыгы әмәлләп куйдылар. Алай гына да түгел, әлеге мәйданчыкта бу атнада Татарстан беренчелеге уеннары узачак әле. Татарстанның ни кырыс футбол федерациясе шундый рөхсәт биргән икән, димәк, футболчыларыбызның тырышлыгы югары дәрәҗәдә лаеклы бәясен алган, дияргә була. Шуңа да без, җанатарлар, трибуналарны буш тотмыйк: район беренчелеге матчларына да йөрик, 11-12 июльдә яраткан “Факел”ыбыз өчен дә тавышларыбызны кызганмыйк.

Илназ МӨБАРӘКШИН

**ЧАКЫРУ**

**ЧЕМПИОНАТНЫҢ БЕРЕНЧЕ ӘЙЛӘНЕШ РАСПИСАНИЕСЕ**

**IV тур**

**14.07 – АТП-2-“Сахарник”;**
**15.07 – АТП-1-НГДУ.**

**V тур**

**22.07 – Егоркино-“Сахарник”;**
**23.07 – НГДУ-АТП-2.**

**Уеннар аэропорт һәм Егоркино мәйданчыкларында 18.00да башлана.**

БУ НИ БУ?

# ”Чистартканнар”...

**16 июнь, Рамазан аеның беренче көнендә газета сайтына Түбән Нурлат микрорайонындагы зираттагы тәртипсезлекләр турында фотохәбәр керде.**

– Якыннарыбызның каберләрен таба алмагач, утырып еладык, әйтерсең, зират өстеннән яу үткән, – дип яза авыл халкы. – Тәртип салырга дип алынган микрорайонның территориаль җәмәгать советы җитәкчелеге зиратта чын вандаллык китереп чыгарган. Бәлки изге нияттән эшләнгән гамәл дә булгандыр, чиста булсын дигәннәрдер. Әмма зираттагы хәлләрне күреп, хәйран калдык. Мәрхүмнәр рухыннан көлү була түгелме соң бу? Безнең кебек якыннары каберен таба алмаучылар шактый. Безгә кемгә мөрәҗәгать итәргә, бу тәртипсезлекне ничек бетерергә икән?

**Ред.** *Әлеге фотофакт микрорайонда яшәүчеләрнең зары түгел, ә җан авазы. Бер-ике кабер генә зыян күрсә бер хәл дә бит, тик менә андыйлар чамадан тыш күп булгач, бу хәлне санитар чистарту дип ничек аңларга?! Зират территориясендә тулы тәртип ясарга алынган җитәкчеләрнең изге нияте күз яшьләре белән тәмамланыр дип кем уйлаган? ТОС җитәкчелеге әлеге эшкә алынганда, авылның аксакаллары белән киңәшеп, халык өмәсе итеп үткәрүне ни өчендер кирәк тапмаган, күрәсең. Сораштырулардан күренгәнчә, авыл халкы әлеге чисталык акциясе хакында белми дә калган икән. Каберләр өстенә техника кертеп чистартуны да аңлап булмый, юкса, районның башка авылларында татар зиратларында өмәләрне халык җыеп, кул көче белән үткәрәләр бит. ТОС җитәкчесе халык белән тыгыз элемтәдә торып, киңәшләшеп эшләсә, чардуганнар, кабер ташлары аунап ятмас иде, мөгаен. Мәңгелек йорт һәркемнән хөрмәт көтәргә хаклы.*



”ЧИСТАРТУДАН” СОҢ ЗИРАТ ШУНДЫЙ ХӘЛГӘ ТӨШКӘН

ГАДӘТТӘН ТЫШ

# Ваемсызлык хаталарны кичерми

**Нурлатта 5 катлы йортның дүртенче каты тәрәзәсеннән бер сабый егылып төшкән.**

Шөкер, бала зыян күрмәгән. Әмма бу бердәнбер очрак түгел икән. Белгечләр әйтүенчә, аеруча җәйге чорда 3-5 яшьлек балалар катнашында шундый бәхетсезлек очраклары еш була, ди. Кызганыч, мондый егылып төшүләр күпчелек очракта авыр җәрәхәтләр белән тәмамлана. Медиклар әйтүенчә, ата-аналарның игътибарсызлыгы баланы гомерлек инвалид калдырырга мөмкин.

– Республикада 30 майдан 1 июньгәчә балаларның тәрәзә төбеннән егылып төшүенең 4 очрагы теркәлгән, – дип хәбәр итәләр район мәгариф бүлегендә. Җәрәхәт алган балалар Казан, Әлмәт, Мамадыш һәм Бөгелмә районнарында. Мондый очраклар ата-аналарның үз бурычларын тәгәл үтәмәве хакында сөйли, һәм моның өчен административ җаваплылык та каралган. Шуңа да психологлар ата-аналарга балалары белән иминлек темасына ешрак сөйләшергә киңәш итә.

– Күп очракта мондый хәл олылар балаларны үзләрен генә калдырган вакытта килеп чыга, – диләр балигъ булмаганнар һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия әгъзалары. Әлеге темага балалар бакчаларында ата-аналар җыелышларында да сөйләшүләр узган.

Зилия ӘКСАНОВА

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Берлек авылында** яшәүче **Минҗиһан Фатыйх кызы Ахунҗанованы** 55 яшьлек юбилее белән котлыйбыз. Алдагы гомереңдә җан тынычлыгы, исәнлек-саулык белән, кайгы-хәсрәт күрмичә яшәвеңне телибез.

Без телибез сиңа озын гомер,
Тигез тормыш,
бәхет-шатлыклар.
Еллар үтсә үтсен, тик әлегә
Ашыкмасын әле картлыклар.

**Иң изге теләкләр белән апаң Һаҗәр, җизнәң Сәгыйть.**

**Чулпан мәктәбе коллективы** хөрмәтле **Рәзилә Шакирҗан кызы Вәлиәхмәтованы** 50 яшьлек юбилее белән котлый.

Чын күңелдән сезне
тәбриклибез,
Котлы булсын туган көнегез.
Куанычтан-куанычка атлап,
Шатлык чәчеп, бәхет игегез.
Һәрвакытта көләч, шат, ягымлы,
Сау-сәламәт, таза булыгыз.
Бәхетләрдән-бәхетләргә генә
Алып барсын йөргән юлыгыз.
Туар көннәр, атар таңнар әле
Озайтырлар гомер дисбесен,
Киләчәкнең яктылары килсен,
Җиңүлесе, матур, хислесе!

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*дом, варианты. Т. 8-919-684-40-03.
*дом, ул. Мира. Т. 8-917-397-00-48.
*2-этажный дом, ж/д, все есть. Т. 8-937-600-48-07.
*3-комнатная квартира, ул. Советская, 195 (дача, гараж). Т. 8-927-243-65-08.
*1-комнатная, 2-комнатная квартиры в центре. Т. 8-927-423-80-69 (после 17.00).
*1-комнатная квартира, ул. Советская, 189. Т. 8-927-405-34-83.
*2-комнатная квартира в центре, индивидуальное отопление, 1 этаж, ремонт, 950000 руб. Т. 8-927-243-83-30.
*3-комнатная квартира, гараж, баня, огород. Т.: 8-927-434-34-43, 8-937-616-01-70.
*дом. Т. 8-927-462-17-01.
*участок под гараж с фундаментом, ул. Нурлатская. Т. 8-927-243-65-08. П/с 16-16-03/015/2008-29
*гараж на санях. Т. 8-927-484-36-41.
*2-комнатная квартира, ул. Гиматдинова, 88. Т. 8-929-724-99-95.
*участок с фундаментом, мкр. Нижний Нурлат. Т. 8-927-415-01-51. П/с 16-16-35/017/2011-525.
*2-комнатная квартира, ул. Советская, 143, можно под офис. Т. 8-927-448-62-32.
***2-комнатные квартиры:** ул. Советская, 195, ремонт, 1050 тыс.руб., ул. Гагарина, 2, инд. отопление, 850 тыс.руб.; **дома: коттедж**, ул. Радужная, есть все, коттедж, ул. Юбилейная, новый; **дом**, ул. Кутузова, баня, гараж, 1650 тыс.руб.; недострой, ул. Ипподромная, 1050 тыс.руб.; **коммерческое помещение,** ул. Нурлатская, 31, 1400 тыс.руб., торг. Т. 8-929-727-12-82, Ксения.
*1-комнатная квартира в малосемейке, ул. Советская, 189. Т. 8-927-240-15-78.
*новый дом, без отделки, мкр. Юго-Западный. Т. 8-927-406-17-05.
*кирпичный гараж с документами, 24 кв.м, ул. Гиматдинова, 91 во дворе. Т. 8-927-403-50-37.
*дом, ж/д. Т. 8-9274-31-48-09.
*дом, с. Биляр-Озеро. Т. 8-927-425-10-16.
*жилой дом, ул. Красноармейская, гараж на 2 машины, сарай, теплица, газ, вода. Т. 8-917-393-26-77.

## АВТОТРАНСПОРТ

*«ВАЗ-2106», 2000 г/в, на ходу. Т. 8-937-611-82-91.
*«ВАЗ-2105», 2006 г/в. Т. 8-937-620-04-26.
*«ВАЗ-21140», 2006 г/в. Т. 8-937-292-85-80.
*«Калина», хэтчбек, 2007 г/в, светло-зеленый перламутр, идеальное состояние. Цена 165 тыс.руб. Торг. Т. 8-927-48-000-74.
*«ВАЗ-2107», 2008 г/в, декабрь, 56000 км, инжектор, цена договорная. Т.: 8-927-029-57-42, 8-927-773-69-82.
*«ГАЗель», фермер, 6-местная, кузов 3 м, 2007 г/в. Т. 8-937-285-84-98.
*МТЗ-80 с краном, 1980 г/в. Т. 8-927-484-53-57.
*«ВАЗ-2121 Нива», 2013 г/в. Т. 8-937-287-47-05.
*«КамАЗ», сельхозвариант, 250 тыс.руб. Т. 8-927-036-14-04.
*МТЗ-80, 80000 руб. Т. 8-937-600-49-27.

## ДРУГОЕ

*ШИКӘР КОМЫ-2230, ОН-970, «Юмарт» кибете. Т. 8-927-445-68-55.
*куры-молодки, бройлеры, несушки, утки, гуси. Т. 8-927-483-06-10. 8-917-293-27-47.
*бычки (молодняк) от 2 до 5 месяцев. Т. 8-927-870-58-98.
*утки, гуси, молодки, бройлеры. Доставка. Т.: 8-937-286-57-23, 8-937-621-81-57.
*дрова. Т. 8-937-003-27-27.
*доски осина, сосна, брусья 6 метров. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.
*ПГС, песок, глина, перегной, грунт от 3 т. Т. 8-927-424-02-83.
*ПГС, бут, песок. Т. 8-937-617-11-21.
*ПГС, бут, песок. Т.: 8-927-675-54-96, 4-37-14.
*ПГС, песок, бут, цемент, керамзит, щебень. Т. 8-927-401-51-91.
*спальный гарнитур, мягкая мебель. Цена при осмотре. Т. 8-927-406-50-51.
*Камышлинский инкубатор реализует подрощенных бройлеров. Т.: 8-937-620-80-30, 4-35-47 (Румия).
*сено, солома, телята мясной породы. Доставка. Т.: 8-909-345-99-77, 8-937-343-80-22.
*картошка. Т. 8-937-581-93-57.
*дрова. Т. 8-927-414-61-34.
*сруб бани под ваш размер и комплект досок к бани. Т. 8-927-419-57-81.
*пенополистироловые блоки. Т. 8-937-779-60-63, 8-917-865-63-30.
*куры-молодки, утята, муларды. Т.: 4-35-11, 8-927-422-92-58.
*корова черной масти, первотелка. Т. 8-927-428-95-83.
*говядина (молодняк) частями. Т. 8-937-286-56-64.
*холодильник двухкамерный, б/у. Т. 8-927-462-13-51.
*песок, ПГС от 3 тонн. Т. 8-927-244-84-71.
*вагон (3x11), 50000 руб., торг. Т. 8-917-392-09-02.
*ПГС, бут, песок. Т. 8-917-936-04-05.
*срубы 7,50мx8,00м, 5,50x3,50м. Т. 8-937-283-19-51.
*доски (осина) 25, 30, 4-метровые, дешево. Доставка. Т. 8-937-575-23-95.
*сруб (3,5x3,5), б/у, полы, крыша. Т. 8-927-241-17-90.
*двухкамерный холодильник, детская кроватка (качалка). Т. 8-927-031-23-28.
*б/у силикатный кирпич, 6 руб. Т. 8-937-600-49-27.
*сено луговое в тюках. Доставка. Т. 8-927-470-08-25.
*дрова. Т. 8-937-617-11-21.
*ПГС, песок, бут. Т. 8-987-413-91-33.
*тумба-шкаф под ТВ, б/у. Т. 8-927-671-73-41.

## РАЗНОЕ

*Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.
*Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.
*услуги сварщика (любой сложности). Т. 8-937-004-40-78.
*ремонт пластиковых окон, москитных сеток. Т. 8-927-249-54-24.
*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.
*установка окон, дверей, откосов. Т.: 8-927-671-26-59, 8-987-189-59-02.
*фундаментные работы любой сложности. Т. 8-937-280-67-25.
*услуги электрика. Т. 8-937-614-70-15.
*грузоперевозки, «ГАЗель», 4 м, 16 куб. Т. 8-927-247-12-61.
*копаем, чистим колодцы. Т.: 8-986-711-25-32, 8-929-723-88-60.
*ремонт квартир. Т. 8-927-446-99-98.
*быстро, качественно плитка, мозаика, все виды отделочных работ. Т. 8-987-971-15-18 (Геннадий).
*ремонт холодильников. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.
*отопление, водопровод, сантехника, недорого. Т. 8-937-772-43-81.
*услуги электрика. Т. 8-987-418-35-00.
* Обшивка домов, кровля и другие строительные работы. Т. 8-9274-222-633.
* Утерянный техпаспорт и водительское удостоверение на имя Айрата Вазировича Халиуллина прошу вернуть за вознаграждение. Т. 8-9274-222-633.
*ремонт, настройка компьютеров, ноутбуков, Wi-Fi, Интернета. Т. 8-937-0051-451.
*ежедневно Нурлат-Самара, автовокзал, глазные клиники. Т. 8-927-031-29-33.
*копаем, чистим колодцы. Т. 8-937-776-79-45.
*услуги каменщика, выполняем бетонные работы. Т. 8-937-294-65-52.
*ремонт пластиковых окон, москитных сеток. Т. 8-927-249-54-24.
***токарные работы по металлу. Т. 8-927-405-40-01, Дмитрий.**
*ремонт холодильников на дому. Т. 8-927-419-56-48.
*срублю сруб под ваш размер. Т. 8-937-283-19-51.
***ремонт, настройка компьютеров, ноутбуков, Wi-Fi, Интернета. Т. 8-937-0051-451.**
*грузоперевозки «ГАЗель». Т. 8-987-006-28-73.
*ремонт ванных комнат и санузлов. Гарантия 3 года. Качество. Т. 8-937-770-88-33.

## ТРЕБУЕТСЯ

*продавец-консультант (двери). Оклад + %. Т. 8-927-430-93-93.
*столяр-станочник, специалисты по деревообработке и отделки. Т. 8-939-733-23-36.
*массажист. Т.: 2-43-03, 2-43-04.
*уборщики (-цы) в г.Казань. Вахта. 15/15. З/п 13 000,00 руб. Общежитие. Т. 8-917-915-08-32.
*в строительно-монтажную организацию инженер-сметчик с опытом работы. Т.: 2-56-66, 8-927-417-39-99; *машинист на бульдозер Т-170. Т.: 2-56-66, 8-937-585-56-16.
*водитель кат. «Е». Т. 8-927-670-78-67.
*школе №1 г. Нурлат учитель технологии. Обязательно педагогическое образование и творческий подход к работе. Т. 2-39-43.
*в ООО «Стройсервис-Бурение» моторист ЦА. Т. 8-927-476-42-19.
*водители на «УАЗ» молоковоз, разнорабочие, сыровары. Т. 8-927-438-55-00.

## КУПЛЮ

*Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.
*КЫЙММӘТКӘ АВТО САТЫП АЛАМ. Т. 8-937-588-36-46.
*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.
*баллоны кислородные, углекислотные. Т. 8-987-292-01-10. ООО «ГК «Втормет».
*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.
*пух гусиный, утиный, старые подушки, перины. Т. 8-987-062-55-26.
*«Лада Калина», универсал или седан, не старше 2012 г/в, один хозяин. Т. 8-92-97-27-55-16.

## СДАЮТСЯ

*в аренду помещения в новом торговом центре с. Челно-Вершины, от 10 до 700 кв.м. Т. 8-937-645-78-42.
*квартира посуточно, командировочным. Т. 8-927-456-05-69.
*1-комнатная квартира, центр. Т. 8-937-626-71-18.
*квартира. Т. 8-937-285-79-84.

## СНИМУ

*1, 2-комнатную квартиру на длительный срок. Т. 8-937-074-99-54.
*1-комнатную квартиру. Т. 8-927-671-49-57.

ДВЕРИ ЭКОНОМ
сеть дверных магазинов
Реклама
ВХОДНЫЕ, МЕЖКОМНАТНЫЕ, БАННЫЕ ДВЕРИ.
*Доставка в кратчайшие сроки (от 1-2 дней). Установка.*
Цены г.Самары и Казани.
Ул. Гиматдинова, 52, 1 этаж (вход в БТИ).
**8-937-583-45-17, 8-927-439-17-06.**

ЖБ КОЛЬЦА.
ДОСТАВКА. УСТАНОВКА.
Т. 8-927-403-51-99.

ПАМЯТНИКИ –
мрамор, гранит.
Фото на граните.
Доставка по городу бесплатно.
Ул. Ленинградская, 14.
**8-987-420-05-97.**

**УСЛУГИ АВТОКРАНА, 25 т., вылет стрелы 21 м.**
**8-927-444-70-80.**

12+ "ТНТ-Нурлат" тәкъдим итә

**13 ИЮЛЬ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.

**15 ИЮЛЬ**
"Нурлат хәбәрләре",
"Татнефть" хәбәрләре.

**17 ИЮЛЬ**
"Нурлат хәбәрләре".
"Сиңа дигән җырым", музыкаль тапшыру

Программалар **19** сәгатьтә башлана. **14, 16, 18** июльдә иртәнге **7**дә кабатлап күрсәтелә.

**«ДОБРАЯ ПОДУШКА» - реставрация подушек. Увезем, привезем по городу бесплатно. Работаем с 9.00 до 18.00 без выходных.**
**8-927-436-01-96, 8-937-296-29-53.**

**ПЕНОИЗОЛ. УТЕПЛЯЕМ СТЕНЫ, ПОТОЛКИ**
**ЖИДКИМ ПЕНОПЛАСТОМ**
**8-937-600-33-02,**

**ПРОДАЕТСЯ**
ОСП-ПЛИТЫ,
ГИПСОКАРТОН.
**Т.: 2-04-68,**
**8-927-413-69-82.**

**ТЕПЛИЦЫ ОТ ЗАВОДА ПО ОПТОВЫМ ЦЕНАМ,**
**3*4 - 12000, 3*6 - 15000, 3*8 - 18000.**
**Спешите, количество ограничено!**
**Акция действует с 10.06.15 по 31.07.15.**
**Подробности акции по тел.: 89270409737, 89179239582, 89600374342.**
**Организатор: ООО «БулгарТрейд».**

**ООО «МИР КРОВЛИ»**
**реализует**
ПРОФНАСТИЛ С9, С20, С21, НС44, Н60, Н75 (оцинкованный и окрашенный), длина до 12 метров, металлочерепицу, металлосайдинг, металлоштакетник, профильную трубу, гладкий лист, доборные элементы. Утеплитель. Парогидроизоляция.
Поликарбонат. Теплицы.
Доставка по городу бесплатно.
Гарантия на всю продукцию.
**Т.: 8-927-826-53-32, 8-937-273-87-15, 8(84235) 2-75-35, 8(84235) 2-72-25.**
**E-mail: mir-krovli73@bk.ru**

Только **1 и 2 августа** на территории школы №4 (Нурлат, ул. Дружбы, 68) пройдет ярмарка школьной одежды от Ульяновской фабрики *«ЭЛЕГАНТ»* по ценам 2014 года.
**1 августа - с 8 до 19 ч.**
**2 августа - с 8 до 16 ч.**

ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА ЛИДЕР
KBE
Жалюзи 700 руб.
Теплые откосы
Отделка уличных откосов
Двери металлические, межкомнатные
Натяжные потолки (Германия) 320 руб.
Владельцам коттеджей особые условия
НОВЫЕ ЦЕНЫ
СКИДКИ БОЛЬШЕ НЕ НУЖНЫ
Москитные сетки в подарок
Подробности по т.: 8-927-246-52-50 (84345) 9-27-95
Гарантия 5 лет
М-н «Акватерм», 2 этаж
Кредит предоставлен АО «ОТП БАНК»
Реклама

**Магазин «РОЗАЛИЯ»**
*Большое поступление мебели производства Белоруссии, Калининграда, «Шатура» и т.д. Кредит, рассрочка (предоставляют ООО «Хоум Кредит энд Финанс Банк», ООО «Русфинанс Банк»).*
**Ул. Хамадеева, 15А.**
**2-37-04.**

ОО «Гарантия качества» предлагает ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА европейского качества по доступной цене заводского производства.
Рассрочка без %, без участия банка.
Т. 8-927-405-53-52.

# БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА


## Кредит на все случаи жизни

Выдаем деньги даже при наличии кредитов в других банках
Учитываем неподтвержденные доходы
Возраст заемщика до 80 лет

Нурлат, Карла Маркса, 19 | 8-19, ежедневно

ПРОБИЗНЕСБАНК (84345) 264-74 круглосуточно, бесплатно

Лайф Финансовая группа

ОАО АКБ "Пробизнесбанк". Кредит выдается по усмотрению банка. 80 лет на момент погашения кредита. Реклама.

banklife.ru

Ген. лиц. №2412 от 28.04.2003 г.

**КОЕЛАР БОРАУЛАУ.**
РАЙОН БУЕНЧА КОЕ БОЖРАЛАРЫН КИТЕРЕП БИРҮ – ТҮЛӘҮСЕЗ.
**Т. 8-9274-233-978.**

АССОРТИМЕНТТА
**КИРПЕЧ, ГАЗОБЕТОН (ТЕПЛОН, УНИБЛОК), ҖИЛЕМ.**
Т. 8-927-440-44-99

ДОСТАВКА ПЕРЕГНОЙ, ЧЕРНОЗЕМ, ГРУНТ, ПЕСОК, ПГС, ДРОВА КОЛОТЫЕ, ЧУРБАКАМИ И ДЕФЕКАТ
8-937-280-94-84.

**ПРИЦЕПЫ.**
**г.Саранск, г. Курган.**
**8-927-736-59-42.**

**ВНИМАНИЕ!!!**
**Только с 1 по 31 июля 2015 г.**
Компания "Оконные системы"




**Окно 1300x1400**
Подоконник 300 мм
Отлив 150мм
Монтаж с демонтажем
При заказе более 2-х окон:
**ПОДАРОК** до **1000р с окна***

| Rehau | KBE | Montblanc | Exprof |
|---|---|---|---|
| 7700руб | 7200руб | 6500руб | **6000**руб |

т. 8-927-742-66-67, 8-908-383-89-98
*Подробности по указанным телефонам. Организатор: ООО "СВК". Реклама

**МАГАЗИН «СПОРТТОВАРЫ»**
- ТРЕНАЖЕРЫ
- САМОКАТЫ
- ВЕЛОСИПЕДЫ
- РОЛИКИ
- МЯЧИ
- ФИТНЕС
- КОНЬКИ
- БОКС
И ДР. СПОРТИВНЫЙ ИНВЕНТАРЬ.
Мини-рынок (мясокомбинат), центральный вход.

**ПОМОЩЬ В ОФОРМЛЕНИИ МАТЕРИНСКОГО КАПИТАЛА.**
8-927-483-05-33
(Алмаз).

**Аксубаевский инкубатор реализует подрощенных индюков, бройлеров, утят.**
Т. 8-927-671-64-51.

**Центр. Аптека № 94** (г. Нурлат, ул. Гагарина, д. 10)
**16 июля с 9.00 до 10.00 ч.**
РАДУГА ЗВУКОВ
ВЫСТАВКА-ПРОДАЖА
**СЛУХОВЫЕ АППАРАТЫ**
(заушные, карманные)
НЕ ТРЕБУЕТСЯ СПЕЦИАЛЬНАЯ ПОДГОТОВКА
Цена: от 6900 до 11500 руб. ГАРАНТИЯ
ЦИФРОВЫЕ (пр-ва Дании, Германии, России )
Цена: от 12800 до 15500 руб. Товар сертифицирован.
Справки и заявки (+ по району)
по тел: 8-901-866-81-57
Сдайте один старый аппарат и получите скидку при покупке нового 7%.*
*Полную информацию об организации акции, правилах проведения, сроках, месте можно узнать по адресу и телефону.
ОГРН 304183133700096 от 31.03. 2003 г., ИП Вилков В.А., ИНН 183100561312.
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ, НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА
РЕКЛАМА

**БАВАРСКИЕ ОКНА**
Тепло и уют Вашего дома.



- Пластиковые окна, лоджии, двери;
- Металлические и межкомнатные двери;
- Арки
- Горизонтальные и вертикальные жалюзи;
- Автоматические ворота;
- ОСП, гипсокартон;
- Теплицы
- Натяжные потолки



СКИДКИ – 1000 руб. на КАЖДОЕ изделие *
**МОСКИТНАЯ СЕТКА В ПОДАРОК**
Кредит**
Доставка и выезд инженера по замеру по г.Нурлат осуществляется - БЕСПЛАТНО!
Наш адрес: г.Нурлат ул.Советская, 92.
Тел.89370085308, 89274136982, 2-04-68



*скидки действуют на пластиковые изделия в период с 01.07.15 по 31.07.15 г. Условия у продавцов. Организатор: ИП Чванова Л.П.
**кредит предоставляется АО «ОТП Банк».
Реклама

**Утепление домов жидким пенопластом.**
**Закачиваем в пустоты стен.**
**8-917-909-18-02**
**8-927-246-84-63**
*Гарантия качества.*
*Большой опыт работы.*

**ПЕЧАТНЫЙ САЛОН Г.НУРЛАТ ПРЕДЛАГАЕТ ВСЕ ВИДЫ**
*НАРУЖНОЙ РЕКЛАМЫ:*
*- РЕКЛАМНЫЕ БАННЕРЫ;*
*- ВЫВЕСКИ НА УЧРЕЖДЕНИЯ;*
*- ИНФОРМАЦИОННЫЕ СТЕНДЫ;*
*- ПЛАНЫ ЭВАКУАЦИИ;*
*- ТАБЛИЧКИ ОФИСНЫЕ;*
*- АДРЕСНЫЕ ВЫВЕСКИ НА ЖИЛЫЕ ДОМА И МНОГОЕ ДРУГОЕ.*
Типография полного цикла. Изготовим печати, штампы, факсимиле.
**Ул. К.Маркса (за музыкальной школой).**
**Т.: 2-04-12, 8-9274-87-27-87.**

**Даём заём!**
Реклама
быстрое решение
- Под зарплату
- Пенсионерам
- Под залог недвижимости, автомобиля, ПТС

г.Нурлат, ул. К.Маркса, 41, ТД "Персона", офис 108.тел.(84345) 2-32-92

ООО «Заем-16» свидетельство о внесении сведений в государственный реестр микрофинансовых организаций. ФСФР РФ. за №651303392003211 от 21.05.2013 г. ООО «Заем-16» выдает займы при положительном рассмотрении заявки: до 10000 руб. на срок от 7 до 60 дней под 1,5% в день, от 11000 до 100000 руб. на срок от 2 до 12 месяцев под 9% в месяц из расчета начисления % на остаток суммы ежемесячно. За каждый день просрочки пенни 0,1% суммы к оплате. Данное предложение не является публичной офертой.
ООО "Заем-16"

**ОТДЫХ НА ЧЕРНОМОРСКОМ ПОБЕРЕЖЬЕ**
С выездом из г.Нурлат на комфортабельном автобусе.
Жилье + питание.
Продолжается набор на 11, 21, 31 июля и 10, 20, 30 августа.
**8-927-034-43-93,**
**8-927-418-72-22.**

**НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ**
*любой сложности.*
**8-9600-33-77-55.**

**ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА «KRAUSS»**
**С 1 января по 31 декабря 2015 г. при заказе 5 окон, 6-е в подарок***
**Деревенские окна по 2000 руб.**
**Откосы, подоконники, москитные сетки.**
**Работаем по всему Татарстану.**
**Рассрочка без % (без участия банков).**
***подробности по т.: 8-9274-000-606, 8-9272-449-000.**
**ИП Ахметов Ф.Ф.**

**М-Н «КОЛЬЦО»**
- цемент «Жигулевский» 50кг;
- ТЕПЛИЦЫ;
- газобетон;
- доломитовый блок;
- кирпич в ассортименте;
- сухие смеси;
- кольца для колодца и канализации.

**г.Нурлат, мкр. Западный («Афганский»), напротив АЗС-Татнефть.**
**8(84345)2 80-57, 8-9276-755-091.**

**ООО «ВСЕ ДЛЯ КРОВЛИ»**
Профнастил С-8, С-9, С-10, С-20, С-21
Оцинкованный, окрашенный, гладкие листы.
Сайдинг металлический, виниловый.
Утеплитель, водосток, металлоштакетник.
Профиля, узоры, доборные элементы.
Любой сложности. На складе и под заказ С-9 цинк в наличии любых размеров.
**Доставка.**
*г. Нурлат, ул. Куйбышева, 36 (около ж/д вокзала)*
**Т.: 8-929-726-57-97, 2-01-26.**

**К ВАШИМ УСЛУГАМ**
– Ремонт и замена автостекол
– Бронирование фар, антигравийка
– Полировка кузова
– Химчистка салона
Обращаться: ул.Чапаева, 19.
**Т.: 8-927-673-75-67,**
**8-917-861-37-78.**

Мы делаем вашу жизнь прочнее
**склад профнастила**
Тел.: 8-927-423-72-72
* ПРОФНАСТИЛ, ШТАКЕТНИК
* МЕТАЛЛОЧЕРЕПИЦА
* САЙДИНГ
* ДОБОРНЫЕ ЭЛЕМЕНТЫ

**склад металлопроката**
Тел.: 8-927-038-37-37
* ПРОФИЛЬНЫЕ ТРУБЫ
* ШВЕЛЛЕРА
* АРМАТУРА, УГОЛОК

**профнастил от 170 р./кв.м.**
г. Нурлат, ул. Гиматдинова (напротив нефтебазы)
Реклама

**КОЕЛАР БОРАУЛАУ**
Ямобур хезмәтләре, төрле диаметрдагы кое бөҗралары.
Район буенча китереп бирү бушлай.
Т.: 8-927-249-25-64.

**Автошкола НУДО ДЮАШ**
**проводит набор курсантов для обучения водителей категории «В».**
Положительное заключение ГИБДД.
**2-33-21, 8-927-240-88-02.**
**Лиц. 4952, выд. Минобразования и науки РТ 17.04.2013 г.**

**«БАЛКОН СТРОЙ» НАМУСЛЫ ЭШЛИБЕЗ**
Пластик, алюминий рам-купелар
* Рам өчен каркас + түбә (теләсә нинди)
* Балконнарны озынайтабыз һәм киңәйтәбез
* Тышлау, тәрәзә төпләре, козыреклар
* Күпьеллык тәҗрибә, ГОСТ буенча монтаж һәм демонтаж
* Килешүләрне өйгә килеп төзибез, % сыз бүлеп түләү (банклар катнашыннан башка)
* Ташлама (пенсионерлар һәм инвалидларга)
* Москит челтәре, үлчәм алу, китерү һәм куеп бирү түләүсез
* 5 ел гарантия.
Т.: 8-927-475-22-15, 8-917-896-17-73.

**«ФАВОРИТ» ТӘРӘЗӘЛӘРЕ**
- ПЛАСТИК ТӘРӘЗӘЛӘР
- АВТОМАТИК КАПКАЛАР
- ҖЫЛЫ ОТКОСЛАР, ЖАЛЮЗИ
-ҖӨЙСЕЗ ТАРТТЫРЫЛМА ТҮШӘМНӘР
***КРЕДИТ, БҮЛЕП ТҮЛӘҮ***
Кредитны «ОТП Банк» АҖ банкы тәкъдим итә, бүлеп түләү банклар катнашыннан башка.



Реклама
**Нурлат, «Татфондбанк» ишегалдында**
**8-9274-849-222, 8-9276-727-807.**

**СТЕНОВЫЕ БЛОКИ**
400x200x200 – 40 руб.
400x200x120 – 32 руб.
Используются для строительства домов, бань, сараев, гаражей.
Доставка от 1080 шт. по г.Нурлат и Нурлатскому району бесплатно.
8-902-337-19-37, 8-848-250-01-70.




Реклама

**«МИР КРОВЛИ И ФАСАДА»**
**Профнастил, м/черепица, сайдинг всех видов, гл.лист, крепеж, утеплители, пленки. Низкие цены. Кредит АО «ОТП Банк», АО «Альфа-Банк». Доборные элементы. Кровельные работы. Ул. Нурлатская, 15.**
**Т. 8-927-671-84-84.**



**Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" АҖ** www.tatmedia.ru www.nurlat-tat.ru **Реклама хезмәте телефоны:** 8 (84345) 2-36-12

"Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасы
Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

"Татмедиа" АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир С.Н. Хәйруллина
Тел.: 2-36-14

**Редакциянең адресы:**
423040, ТР, Нурлат шәһәре, К.Маркс ур., 19
**Электрон адрес:** e-mail: redak@list.ru
**Телефоннар:** 2-36-12 – җаваплы сәркатип, реклама бүлеге, факс
2-36-20 – рус бүлеге
2-36-13 - корреспондентлар
2-25-88 – бухгалтерия

**Нәшер итүче:**
"ТАТМЕДИА" АҖ 420097, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2 йорт.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы (Татарстан) идарәсе тарафыннан 2013 елның 16 маенда теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы: ПИ № ТУ 16-01018
Бу сан "Татмедиа" АҖ филиалы – "Идел – Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды
Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2.
Басуга тапшыру вакыты: график буенча – 14.30, фактта – 14.30

татмедиа

Тираж сертификатлаштырылган
Тираж - 1700

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булып чыгарга мөмкинлеге юк.
**Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
Реклама белдерүләренең төгәллеге өчен реклама бирүче үзе җаваплы.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Газета **чәршәмбе** һәм **җомга** чыга.
Заказ №5958
Язылу индексы – 16185
Бәясе ирекле.
12+


© Язмаларны күчереп бастыру редакциянең язмача рөхсәте белән генә мөмкин.